**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　КАРАР

2019 елның 18 декабрендәге　　　　　　446 №

Әлки муниципаль районының
гомуми белем бирү оешмаларында
укучыларның һәм инвалид балаларның
туклануын оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Әлки муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансны туклану нормаларының үтәлешен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы «2020 елга айлык акчалата түләүләр һәм башка түләүләр турында» карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан алып 31 нче декабренә кадәр Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һәм инвалид балаларны кайнар аш белән тәэмин итүне 7 сум 70 тиен күләмендә субсидия һәм һәр уку көненә ата-аналар түләве суммасына оештырырга.

1.2 Үз составында 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк укучы бала булган гаиләләрдә , шулай ук инвалид балалар өчен җирле бюджет акчалары исәбеннән исәбеннән кайнар туклану (иртәнге ашлар) оештырырга:

а) авыл мәктәпләре өчен-30 сум 40 тиен, шул исәптән 7 сум 70 тиен - субсидия, 22 сум 70 тиен-җирле бюджет хисабына.

1.3. Кайнар аш белән тәэмин итүне оештырганда үз составында 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган, шулай ук Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә бушлай тукланучы инвалид балалары булган гаиләләрнең санына таянып эш итәргә кирәк (1 нче кушымта).

1.4. Үз составында 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә бушлай тукланучы инвалид балалары булган гаиләләрнең санын исәпкә алуны тәэмин итәргә.

2. «Әлки муниципаль районының финанс-бюджет палатасына» уку вакытында Әлки муниципаль районы бюджетында 2020 елга каралган ассигнованиеләр чикләрендә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен кайнар тукпануны оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

3. «Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесе Савинов А.А.:

3.1 Укучыларның кайнар ашын оештыруга бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

3.2 Витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрнең эчтәлеге буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә;

3.3 Мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашлары ассортиментын баету буенча эшне көчәйтергә;

3.4 Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез китерелүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

4.1 Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

4.2 «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПин 2.4.5.2409-08, «Санитария кагыйдәләрен үтәүне һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чараларны үтәүне җитештерү контролен оештыру һәм уздыру» СП 1.1.1058-01 һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль заказчылары тарафыннан азык-төлек продуктларын кабул итү Регламенты нигезендә гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар туклануны оештыруга производство контролен үткәрергә.

5. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Йосыпов

башкаручы: Бухарова Н.А.
21-6-97

1 нче кушымта

**2020 елда Әлки муниципаль районының җирле бюджеты хисабына 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләрдәге укучыларга бушлай туклану бирүгә бәйле чыгымнарны өстәмә финанслау күләме**

| № | Учреждение исеме | 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдә укучылар саны | Суммасы, сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | Алпар урта гомуми белем бирү мәктәбе | | - |
| 2 | Базарлы Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе | **25** | **119 175,00** |
| 3 | Нәби Дәүли исемендәге Базарлы Матак гимназиясе | **18** | **85 806,00** |
| 4 | Борискино урта гомуми белем бирү мәктәбе | **11** | **52 437,00** |
| 5 | Түбән Әлки урта гомуми белем бирү мәктәбе | **10** | **47 670,00** |
| 6 | Яңа Салман урта гомуми белем бирү мәктәбе | **11** | **52 437,00** |
| 7 | Иске Матак урта гомуми белем бирү мәктәбе | **20** | **95 340,00** |
| 8 | Хузангай урта гомуми белем бирү мәктәбе | **10** | **47 670,00** |
| 9 | Чуаш Кичүе урта гомуми белем бирү мәктәбе | **15** | **71 505,00** |
| 10 | Чуаш Борнае урта гомуми белем бирү мәктәбе | **20** | **95 340,00** |
| 11 | Юхмачы урта гомуми белем бирү мәктәбе | **20** | **95 340,00** |
| 12 | Әхмәт төп гомуми белем бирү мәктәбе | **4** | **19 068,00** |
| 13 | Югары Әлморза төп гомуми белем бирү мәктәбе | | - |
| 14 | Каргалы төп гомуми белем бирү мәктәбе | **3** | **14 301,00** |
| 15 | Түбән Кәчи төп гомуми белем бирү мәктәбе | **3** | **14 301,00** |
| 16 | Иске Салман төп гомуми белем бирү мәктәбе | **5** | **23 835,00** |
| 17 | Иске Тахтала төп гомуми белем бирү мәктәбе | **12** | **57 204,00** |
| 18 | Иске Чаллы төп гомуми белем бирү мәктәбе | **10** | **47 670,00** |
| 19 | Иске Әнҗерә төп гомуми белем бирү мәктәбе | **2** | **9 534,00** |
| 20 | Татар Борнае төп гомуми белем бирү мәктәбе | **2** | **9 534,00** |
| | **БАРЛЫГЫ** | **201** | **958 167,00** |